СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Апаз авыл җирлеге советы**
**карары**

**“29” ноябрь 2023 ел** **№ 132**

**Физик затлар милкенә салым турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасының 2014 елның 30 октябрендә кабул ителгән “Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар милкенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында”гы 82-ТРЗ Законы буенча Апаз авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Физик затларның Апаз авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләү каралган мөлкәтенә салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын билгеләргә:

1) 0,1 процент:

гаражлар һәм машина кую өчен урыннар, шул исәптән әлеге пунктның 4 пункт астында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан урыннар;

һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше алып бару өчен җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмалары;

2) 0,2 процент:

фатирлар, фатирлар өлешләре;

бүлмәләр;

3) 0,3 процент:

торак йортлар, торак йортлар өлешләре;

объектларның проектлана торган максаты торак йорт булса, төзелеп бетмәгән объектлар;

составына ким дигәндә бер торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекслар,

4) 2 процент

Россия Федерациясе Салым кодексының 378-2 маддәсендәге 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары, Россия Федерациясе Салым кодексының 378-2 маддәсендәге 10 пунктының

икенче абзацында каралган салым салу объектлары, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары;

5) башка салым объектларына карата 0,5 процент.

3. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йортта фатирга милек хокукына ия булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метры кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнгән суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәрберсе өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташлама суммасы уртак милектә катнашучыларның һәрберсе өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пунктка нигезләнеп исәпләнгән ташлама суммасы исәпләнгән салым суммасыннан аның исәбеннән башка артмаска тиеш.

Югарыда күрсәтелгән ташламаны раслаучы документлар буларак җирле үзидарә органы тарафыннан расланган йортка кадастр паспорты яки күп фатирлы бер катлы торак йортлар исемлеге исәпләнергә мөмкин.

4. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итәргә:

4.1. 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны;

4.2. Әлеге пунктның 4.1кече пунктында күрсәтелгән гражданнарның балаларын.

Салым ташламасы салым салынырга тиешле объектларның түбәндәге төрләренә карата бирелә:

– фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;

– торак йорт яки торак йортның бер өлеше;

– гараж яки машина кую өчен урын.

Салым ташламасы, салым ташламаларын куллану өчен нигезләмәләр санына карамастан, салым түләүченең сайлавы буенча, гаиләгә туры килгән һәр төрдән бер объекка карата гына бирелә.

Салым ташламасы Апаз авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче милкендә булган һәм эшкуарлык эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына салым ташламасы бирү турында гариза бирә, шулай ук алар салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга да хокуклы.

Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар булып түбәндәгеләр санала:

– салым түләүче тарафыннан әлеге салым буенча танылган физик затның шәхесен раслаучы документ;

– аның исеменә бирелгән күп балалы гаилә таныклыгы.

Салым ташламасы бирелә торган салым салу өчен сайланган объектлар турында белдерү салым түләүче тарафыннан салым органына 1 ноябрьгә кадәр тапшырыла, ул салым чоры булып тора, аннан башлап әлеге объектларга карата салым ташламасы кулланыла.

5. Апаз авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

– 2015 елның 3 ноябрендә кабул ителгән 13 номерлы “Физик затлар милкенә салым турында”;

– 2018 елның 29 ноябрендә кабул ителгән 132 номерлы “Апаз авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 ноябрендә кабул ителгән 13 номерлы “Физик затлар милкенә салым турында”гы карарына үзгәрешләр кертү турында;

- 2019 елның 16 октябрендә кабул ителгән 166 номерлы “Апаз авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 ноябрендәге 13 номерлы “Физик затлар милкенә салым турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында;

– 2021 елның 5 маенда кабул ителгән 31 номерлы “Апаз авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 ноябрендәге 13 номерлы “Физик затлар милкенә салым турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында;

6. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов

СОВЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003056